**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йорт дуңгызлары һәм кабан дуңгызлары Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чир таралу куркынычы булу сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында**

Африка дуңгыз чумасы белән чирләүне бетерү һәм чирнең таралуын кисәтү буенча эпизоотиягә каршы һәм профилактика чаралары үтәлү белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 28 гыйнварындагы 37 номерлы боерыгы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә йорт дуңгызлары һәм кабан дуңгызлары Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чир таралу куркынычы булу сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләре чикләрендәге эпизоотия чыганакларында:

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Приволжский авыл җирлегенең Приволжский поселогы Мәктәп урамы, 12 нче йорттагы шәхси ярдәмче хуҗалык территориясе;

«Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Килди авыл җирлеге Килди авылындагы «Пашков Сергей Игоревич» крестьян (фермер) хуҗалыгы территориясе;

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә «Куйбышев» аучылык хуҗалыгы территориясенең төньяк киңлектәге 54.9606750° һәм көньяк озынлыктагы 49.3084830° географик координатларыннан 300 м радиустагы өлеше;

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Бураково авыл җирлегенең Коминтерн поселогындагы Бакча урамында урнашкан 20 нче йортның шәхси ярдәмче хуҗалыгы территориясе;

«Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Алабай» аучылык хуҗалыгы территориясенең «Аэросервис» акционер җәмгыяте тарафыннан файдаланыла торган, төньяк киңлектәге 55,838327° һәм көньяк озынлыктагы 50,823172° географик координатларыннан 300 м радиустагы өлеше;

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә «Куйбышев» аучылык хуҗалыгы территориясенең төньяк киңлектәге 54,964428° һәм

көньяк озынлыктагы 49,189794° географик координатларыннан 300 м радиустагы өлеше;

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Никольский авыл җирлегенең Никольский авылындагы Үзәк урамда урнашкан 24 нче йорт шәхси ярдәмче хуҗалыгы территориясе;

«Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Булдырь авыл җирлегенең Булдырь авылы Ключевая урамы, 7 Б номерлы йорттагы шәхси ярдәмче хуҗалык территориясе;

«Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Масловка авыл җирлегенең Масловка авылы Пролетарская урамы, 39 номерлы йорттагы шәхси ярдәмче хуҗалык территориясе;

б) куркыныч янаган зоналарда:

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Приволжский поселогы, Болгар шәһәре, Ржавец авылы чикләрен кертеп, әлеге пунктның «а» пунктчасы икенче абзацында күрсәтелгән эпизоотия чыганагы белән чиктәш булган, эпизоотия чыганагы чикләреннән ким дигәндә 5 км радиуста урнашкан территория чикләрендә;

«Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Килди, Олан, Федяево, Харино, Карагужа авыллары чикләрен кертеп, әлеге пунктның «а» пунктчасы өченче абзацында күрсәтелгән эпизоотия чыганагы белән чиктәш булган, эпизоотия чыганагы чикләреннән ким дигәндә 5 км радиуста урнашкан территория чикләрендә;

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Кызыл Бистә, Ширбәт, Бугровка авыллары чикләрен кертеп, әлеге пунктның «а» пунктчасы дүртенче абзацында күрсәтелгән эпизоотия чыганагы белән чиктәш булган, эпизоотия чыганагы чикләреннән ким дигәндә 5 км радиуста урнашкан территория чикләрендә;

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Бураково, Кожаевка авыллары, Коминтерн поселогы, Вожи, Әҗмәр авылы чикләрен кертеп, әлеге пунктның «а» пунктчасы бишенче абзацында күрсәтелгән эпизоотия чыганагы белән чиктәш булган, эпизоотия чыганагы чикләреннән ким дигәндә 5 км радиуста урнашкан территория чикләрендә;

«Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Никифорово авылы, Сәртек авылы чикләрен кертеп, әлеге пунктның «а» пунктчасы алтынчы абзацында күрсәтелгән эпизоотия чыганагы белән чиктәш булган, эпизоотия чыганагы чикләреннән ким дигәндә 5 км радиуста урнашкан территория чикләрендә;

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Кызыл Бистә авылы, Красный Вал авылы, Ржавец авылы чикләрен кертеп, әлеге пунктның «а» пунктчасы җиденче абзацында күрсәтелгән эпизоотия чыганагы белән чиктәш булган, эпизоотия чыганагы чикләреннән ким дигәндә 5 км радиуста урнашкан территория чикләрендә;

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Никольский авылы, Гөлеш авылы, Бугровка авылы, Антоновка авылы, Отрада авылы, Татар Такталысы авылы, Мартышачий поселогы, «КИМ» совхозының икенче фермасы поселогы, «КИМ» совхозы поселогы, Гусиха авылы, Ширбәт

авылы, Кызыл Бистә авылы чикләрен кертеп, әлеге пунктның «а» пунктчасы сигезенче абзацында күрсәтелгән эпизоотия чыганагы белән чиктәш булган, эпизоотия чыганагы чикләреннән ким дигәндә 10 км радиуста урнашкан территория чикләрендә;

«Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Булдырь авылы, Чытырчы авылы, Борнаш авылы чикләрен кертеп, әлеге пунктның «а» пунктчасы тугызынчы абзацында күрсәтелгән эпизоотия чыганагы белән чиктәш булган, эпизоотия чыганагы чикләреннән ким дигәндә 5 км радиуста урнашкан территория чикләрендә;

«Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Масловка авылы, Рус Әшнәге авылы чикләрен кертеп, әлеге пунктның «а» пунктчасы унынчы абзацында күрсәтелгән эпизоотия чыганагы белән чиктәш булган, эпизоотия чыганагы чикләреннән ким дигәндә 5 км радиуста урнашкан территория чикләрендә;

в) «Аксубай муниципаль районы», «Алексеевск муниципаль районы», «Әлки муниципаль районы», «Әлмәт муниципаль районы», «Апас муниципаль районы», «Арча муниципаль районы», «Әтнә муниципаль районы», «Балтач муниципаль районы», «Буа муниципаль районы», «Югары Ослан муниципаль районы», «Биектау муниципаль районы», «Чүпрәле муниципаль районы», «Алабуга муниципаль районы», «Зәй муниципаль районы», «Зеленодольск муниципаль районы», «Кайбыч муниципаль районы», «Кама Тамагы муниципаль районы», «Кукмара муниципаль районы», «Лаеш муниципаль районы», «Мамадыш муниципаль районы», «Менделеевск муниципаль районы», «Түбән Кама муниципаль районы», «Яңа Чишмә муниципаль районы», «Нурлат муниципаль районы», «Питрәч муниципаль районы», «Балык Бистәсе муниципаль районы», «Саба муниципаль районы», «Сарман муниципаль районы», «Спас муниципаль районы», «Тәтеш муниципаль районы», «Тукай муниципаль районы», «Теләче муниципаль районы», «Чирмешән муниципаль районы», «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлекләре чикләре кысаларында күзәтчелек зонасында.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә 180 календарь көн дәвамында түбәндәге чикләүләр саклана:

дуңгызларны, 70°C югарырак температурада аларны йогышсызландыруны тәэмин итә торган сәнәгать эшкәртүе узмаган дуңгызчылык продукциясен һәм аларны эшкәртүдән алынган продукцияне әлеге Указның 1 пункты «в» пунктчасында күрсәтелгән территорияләрдән транспортка төяп чыгаруны тыю;

әлеге Указның 1 пункты «б» һәм «в» пунктчаларында күрсәтелгән территорияләрдә дуңгызларны сатуны тыю.

Әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән тыюлар Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 28 гыйнварындагы 37 номерлы боерыгы нигезендә расланган Африка дуңгыз чумасы белән чирләүне бетерү һәм чирнең таралуын кисәтүгә юнәлтелгән профилактика, диагностика, чикләү чараларын һәм башка

чараларны тормышка ашыру, карантин һәм башка чикләүләр кертү һәм аларны бетерү буенча ветеринария кагыйдәләренең 37 һәм 38 пунктлары нигезендә III һәм IV компартментларга караган һәм куркыныч янаган зонадан һәм күзәтчелек зонасыннан чыгарылган хуҗалыклар территорияләренә кагылмый.

3. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йорт дуңгызлары Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чир таралу куркынычы булу сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2022 елның 10 августындагы ПУ-541 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йорт дуңгызлары һәм кабан дуңгызлары Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чир таралу куркынычы булу сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2022 елның 11 августындагы ПУ-548 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йорт дуңгызлары һәм кабан дуңгызлары Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чир таралу куркынычы булу сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2022 елның 12 августындагы ПУ-555 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йорт дуңгызлары Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чир таралу куркынычы булу сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2022 елның 18 августындагы ПУ-563 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йорт дуңгызлары Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чир таралу куркынычы булу сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2022 елның 29 августындагы ПУ-606 номерлы Указы.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2022 ел, 08 октябрь
№ ПУ-723